**Галиуллина Г.Р.**
Казан федераль университеты, Казан

# ТАТАР АНТРОПОНИМИК СИСТЕМАСЫНДА ТӨРКИ ЧЫГЫШЛЫ ТИТУЛЛАР

Борынгы төрки чорда югары катлам вәкилләренең исемнәре составында аерым социаль детерминативлар, титуллар куллану киң таралыш тапкан була. Һуннар чорында ук кабилә башлыкларының Тәңре варислары булуына ышанулар яшәгән. Борынгы рун язма истәлекләрендә, ташка язылган ядкарьләрдә борынгы төркиләрнең юлбашчылары, кешеләр белән идарә итәр өчен, Тәңре тарафыннан сайлап алынганар дигән ышану яшәгән. «Өстә – зәңгәр күк, аста – көрән җир кылынганда, ике арада кеше углы барлыкка килде. Кеше углы өстеннән борынгы бабаларыбыз Бумын каган, Истәми каган идарә иткән. Тәхеттә утырып, төрки халкының илен һәм кануннарын саклаганнар, үстергәннәр» [3: 95].

Төрки чыгышлы исемнәр составында сакланып калган кайбер титулларга тукталыйк. Аларның берише борынгы чорларда гына кулланылып, соңрак әйләнештән төшеп калганнар, кайберләре хәзерге татар телендә ир-ат кушма исемнәрен ясауда катнашып киләләр. Шунысын искәртү кирәк: борынгы төрки телдә исем йөртүченең социаль статусын күрсәтә торган титуллар, әкренләп титул белдергән мәгънәләрен җуеп, исем компоненты роленә күчкәннәр һәм кушма исемнең бер компонентына әверелгәннәр. Борынгы чорда кулланылган кушма төзелешле күп кенә исемнәрнең бер компоненты исем хуҗасының иҗтимагый дәрәҗәсен белдерү өчен кулланылган титуллардан гыйбарәт.

Социаль детерминативлар арасында *бәк* термины аерым урын алып тора. Ул гади халык белән ханнар арасында булган төрки аристократия катламын белдерү өчен кулланылган. Борынгы төрки чорда *бәк* детерминативы кеше исемнәре составында шактый очрый, мәсәлән, *Барс бәк, Орын бәк, Бәк Арслан*. Төрки-татар антропонимиконының соңрак үсеш чорында бу титулның кулланылыш активлыгы югалмый. *Бәк*, аның фонетик

варианты *бу/би* катнашып ясалган ир-ат исемнәре Болгар, Казан, Чишмә археологик ядкарьләрендә сакланып калган. Болгар кабер таш язмаларын өйрәнгән галимнәр фикеренчә, «бәкләр дип Болгарга буйсынган аерым җирләрнең хуҗалары, идарәчеләре аталган, мәсәлән, Алтын бу, Хаҗи бу» [2: 98]. Әкренләп кеше исемен ясый торган компонентка әйләнгән әлеге титул исем йөртүченең социаль хәлен күрсәткән һәм еш кына нәселдән-нәселгә күчкән. Җәмгыять үсешенең борынгырак чорында әлеге детерминат илбашын белдерсә, соңрак кабилә, аерым нәсел башлыгын атау өчен кулланылган. Исем компонентына әйләнүе дә соңрак чорларга карый. Бары тик ир-ат исемнәрендә генә кулланылып, исем йөртүченең югары даирәдән булуына ишарә иткән әлеге компонент төрки-татар антропонимиконында гасырлар дәвамында үз йөзен югалтмыйча кулланыла. Мәсәлән, XVII гасырга караган язма чыганакларда *Биктимер, Бибәк, Алтынбәк, Калбәк, Сәнибәк, Үҗәбәк* һ.б. исемнәр; XIX гасырда *Бәксолтан, Сәитбәк, Солтанбәк, Бикмөхәммәт, Бикбулат* исемнәре; XX гасырда *Илбәк, Нурбәк, Нурбик, Нариманбәк, Бикбулат, Әнвәрбәк* кебек исемнәр.

Хәзерге көн татар исемлеген өйрәнеп һәм татар гаиләләрендә сорашулар үткәреп, без борынгы төрки традицияләр XX-XXI гасыр чикләрендә дә дәвам итә, дигән нәтиҗәгә килдек. Әлбәттә, бүгенге татар кешесе *бәк* сүзен борынгы ышануларга бәйләп карамый, шулай да милли аңыбызда борынгы традицияләр яшәеше сизелә, аерым алганда, ир балага составында *бәк* компоненты булган исемнәрне сайлаган вакытта, татар кешесе балага бәхет, байлык уңыш теләү белән бергә, аның югары дәрәҗәләргә ирешүен дә тели. Соңгысында исә *бәк* сүзенең борынгы төрки чорда яшәгән мәгънәсе реальләшә дә инде. *Бәк* компонентлы исемнәр бары тик ир балаларга кына кушыла. 2000-2010 еллар метрик кенәгәләрен өйрәнеп, без бәк компонентлы түбәндәге исемнәрне очраттык: Айбәк (2005 ел, Арсланбәк (2000, 2005, 2007 еллар), Бибарс (2000 ел), Биктимер (2004 ел), Нурбәк (2007, 2009 ел), Азамбәк (2004 ел).

XX гасырның икенче чирегенә кадәр татарлар арасында *бай*

компонентлы ир-ат исемнәре шактый актив кулланылышта булды. Заманында югары катлам кешеләренең статусы күрсәткече булган *бай* сүзе килеп чыгышы белән *бәк* сүзенә барып тоташа. Аның мәгънәсе «бай, күп, аксөяк» кебек семалардан тора. Төрки мифологиядә ул «изге» мәгънәсенә дә ия була [4: 168]. Бүгенге татар телендә *бай* сүзенең бу мәгънәсе сакланмаса да, башка төрки телләр белән чагыштырып, тарихыбызга кыска гына күзәтү ясау нәтиҗәсендә *бай* компонентлы исемнәрдә төрки бабаларыбызның Тәңрегә булган ышанулары ятуын аңларга була.

Татарлар арасында *бай* компоненты кушылып ясалган исемнәр гаять күп: *Байтимер, Баймөхәммәт, Байназар, Байбакты, Байбулат, Байкилде, Әхмәтбай, Тимербай, Галибай, Миңнебай* һ.б. Күргәнебезчә, әлеге компонент исемнең төрле өлешендә иркен кулланыла. Бу инде аның телгә ныклап урнашкан булуын, озак дәверләр актив кулланылуына дәлил булып тора. *Бай* сүзе һәм аннан килеп чыккан *байан, байат* сүзләре төрки мифологиядә һәм исемнәр системасында киң таралыш тапкан һәм аларның мәгънәви мөмкинлекләре дә зур. Мәсәлән, *Баян* исеме борынгы төрки телдәге *bajan* – *бай* сүзенә барып тоташа. Шушы формада һәм мәгънәдә әлеге сүз хәзерге монгол телендә дә кулланыла. Бүгенге татарлар арасында *Баян* ир балаларга кушыла торган исем санала. Борынгы язма истәлегебез – Йосыф Баласагынлының «Котадгу билиг» әсәрендә «баят» сүзе «тәңре, алла» мәгънәсендә кулланыла: «bajat aty birla sozuq bašladim – баят (тәңре, алла) сүзе белән башладым сүземне».

Башкорт топонимиясен өйрәнгән Г.Х. Бохарова, бик күп фактик материал анализлаганнан соң, *бай* сүзенең «тәңре, алла» мәгънәләрендә кулланылуына ныклы дәлилләр китерә [1: 68].

Төрки мифологиядә Тәңре белән бәйле һәм изгеләштерелгән агач образы киң таралган. Татарлар һәм башкортлар аны байтирәк – изге агач дип йөртәләр. Бу факт тагын бер тапкыр *бай* компонентлы исемнәрнең Тәңре белән, күк белән бәйле булуын исбатлый, шунлыктан *бай* компонентлы исемнәрнең, башлап, югары даирә кешеләре арасында кулланылуын әйтәбез.

Мөгаен, татарларда *бай* сүзенең хуҗа, әфәнде (бай абзый, Гали бай, Муса бай һ.б.) кебек мәгънәләрдә кулланылу нәкъ шуның белән бәйледер.

Ир балага *бай* компоненты белән ясалган исем кушканда, ата-ана баланың бай, көчле булуын, мул тормышта яшәвен теләгән. Ислам дине тәэсирендә *бай* компонентлы исемнәрнең телдә кулланылышы беркадәр кими, әмма аның популярлыгы шулкадәр көчле була, ислам кысрыклавы да аның тулысынча югалуына китерми. Мәсәлән, мөселман исемнәренең татарлар арасында киң тарала башлаган XVIII гасыр рәсми документларында бик күп исем теркәлеп калган: *Асылбай, Аднабай, Байсубай, Дәүләтбай, Илкебай, Илчебай, Илбай, Котлыбай, Морзабай, Уразбай, Урысбай, Исәнбай, Йансубай, Тарбай, Кинҗәбай, Илтүбай, Көчекбай* [5: 59] һ.б. Исем составындагы *бай* сүзе XIX гасыр ахырына үзенең титул мәгънәсен тулысынча югалтып, бары тик ир балаларга кушыла торган исемнәренең бер өлеше генә булып кала. Үз мәгънәсе белән югары катламга ишарә иткән бу исем компоненты тора-бара «мужик, гади халык» исеменә әйләнә, фәкыйрь гаиләләрдә кулланыла башлый. Бу чорга караган язма документларны өйрәнгәннән соң, без укымышлылар арасында, дин әһелләре гаиләләрендә, байлар һәм сәүдәгәр гаиләләрендә *бай* компонентлы исемнәр кушылмаганлыгын, шул ук вакытта крестьян һәм эшче гаиләләрендә бу компонент белән ясалган исемнәргә мөрәҗәгать итү еш күзәтелүен ачыкладык.

XX гасырда *бай* компонентлы исемнәр тулысынча кулланылыштан чыга, әмма XXI гасыр башында традицияне торгызырга омтылу сизелә, аерым алганда, Казан шәһәре ЗАГС архив документларында *Байбулат, Илбай*, *Алтынбай*, *Сагынбай* кебек ир балага кушылган исемнәр теркәлгән.

КУЛЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ:


1. Бухарова Г.Х. Мифопоэтическая картина мира в башкирской топонимии. – Уфа: Изд-во ВГПУ, 2003.
2. Мухаметшин Д.Г., Хакимзянов Ф.С. Эпиграфические памятники города Булгара. – Казань: Тат. кн. изд-во, 1987.

3. Нуриева Ф.Ш. Борынгы төрки тел. Орхон-Енисей язмалары теле (VII-VIII гасырлар). – Казан: Казан ун-ты нәшр., 2007.
4. Потапов Л.П. Алтайский шаманизм. – Л.: Наука, 1991.
5. Хисамова Ф.М. XVIII йөздәге татарча эш кәгазьләренең тел үзенчәлекләре. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1981.